**Математика серләрен дусларына гына ача**

*(Математика. 1,3 класс)*

Шангараева Лилия Рахимзяновна

Арча районы Иске Ашыт төп мәктәбенең I квалификация категорияле башлангыч класслар укытучысы

Соңгы елларда авыл мәктәпләрендә балалар саны кимү азкомплектлылыкка китерде. Бер дәрес эчендә ике класска берьюлы сыйфатлы белем бирү өчен укытучының һәр минуты ныклап уйланылган булырга тиеш. Һәр класс укучысы үз программасын тиешле югарылыкта үзләштерә алсын, игътибарын читкә юнәлтмәсен өчен , укучыларга тәкъдим ителгән биремнәр барлык укучылар да аңларлык, аларны кызыксындырырлык булырга тиеш.

| | | |
|---|---|---|
| Предмет | Математика | Математика |
| Класс | 1  класс | 3  класс |
| Тема | **0 саны һәм цифры** | **Озынлык үлчәү берәмлеге. Метр һәм километр** |
| Дәреснең<br>максаты | 0 саны, цифры белән таныштыру | Яңа озынлык үлчәү берәмлеге км белән таныштыру, км һәм метр арасында бәйләнеш төзү |

| | | |
|---|---|---|
| Дәреснең бурычлары | - 0 санының саннар рәтендәге урыннын табу;<br>- 0 цифрын язарга өйрәтү;<br>- анализлау, гомумиләштерү, күзәтү һәм чагыштыру күнекмәләрен үстерү;<br>- укуга кызыксыну тәрбияләү. | - өйрәнгән үлчәү берәмлекләрен практикада куллануны күзаллау булдыру;<br>- өйрәнелгән озынлык үлчәү берәмлекләре белән бәйләнеш төзү;<br>- теоретик белемнәрне практикада куллана белергә өйрәтү;<br>- арифметик гамәлләрне , мәсьәләләрне чишүдә логик фикерләүне камилләштерү;<br>- телдән исәпләү күнекмәсен үстерү;<br>- иптәшеңә хөрмәт, авырлыкларны җиңүдә бердәмлек тәрбияләү. |
| Дәреснең тибы | яңа белемнәрне формалаштыру | яңа белемнәрне формалаштыру |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | <u>Предмет нәтиҗәләре</u>: 0 санын тану, дөрес итеп язу, саннар рәтендәге урынын белү.<br><u>Шәхсиятле нәтиҗәләр</u>: | <u>Предмет нәтиҗәләре</u>: яңа үлчәү берәмлеге км һәм м арасындагы бәйләнешне аңлап калу.<br><u>Шәхсиятле нәтиҗәләр</u>: |

| | | |
|---|---|---|
| | - геройларга, күршеңә ярдәм итүдә танып – белү инициативасы күрсәтү;<br>- эшчәнлегеңә нәтиҗә ясау;<br>-үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>Метапредмет нәтиҗәләр:<br>танып-белү универсаль уку гамәлләре:<br>- үзеңнең белем дәрәҗәңдә ориентлашу;<br>- укытучы ярдәме белән белгәннәрне яңасын өйрәнгәндә куллану;<br>регулятив универсаль уку гамәлләре:<br>-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;<br>- гамәлләрне таләп ителгән вакытта | - өйрәнелә торган материал белән кызыксыну;<br>- эшчәнлегеңә нәтиҗә ясау;<br>- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;<br>Метапредмет нәтиҗәләр:<br>танып-белү универсаль уку гамәлләре:<br>- гамәлләрне чишүдә кирәкле информацияне табу;<br>- логик фикерләү чылбырын төзү;<br>-анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару.<br>регулятив универсаль уку гамәлләре:<br>- уку гамәлләрен чишкәндә планлаштыру, контрольдә тоту, төзәтүләр кертү;<br>-үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;<br>-бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру; |

| | | |
|---|---|---|
| | башлау һәм тәмамлау;<br>- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү.<br>коммуникатив универсаль уку гамәлләре:<br>-күзаллау, фаразлау;<br>-логик фикер йөртү осталыгы;<br>-күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>-үз фикереңне аңлаешлы итеп әйтү. | -дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау.<br>коммуникатив универсаль уку гамәлләре:<br>- күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү;<br>- күршең белән хезмәттәшлек итү;<br>- фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;<br>-үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау. |
| Предметара бәйләнеш | Сынлы сәнгать, татар теле | Әйләнә-тирә |
| Эш формалары | фронталь, индивидуаль, парларда | индивидуаль, парларда, төркемдә |
| Ресурслар | “Математика” 1 класс, А.Л. Чекин | “Математика” 3 класс, А.Л. Чекин - |

<table>
<tr><td colspan="2"></td><td colspan="2">- русчадан И.Т.Сәгдиева, Р.С.Вафина тәрҗемәсендә, мөстәкыйль эш дәфтәрләре.<br>Компьютер, презентация, санлы җилпәзә, карточкалар, бублик, сушкилар</td><td colspan="2">русчадан И.Т.Сәгдиева, Р.С.Вафина тәрҗемәсендә.<br>Компьютер, презентация, карточкалы биремнәр, Кызыл Калфак, карта</td></tr>
<tr><td colspan="6">Дәресне оештыру структурасы</td></tr>
<tr><td>Дәреснең этаплары</td><td>Укытучы эшчәнлеге</td><td>Укучылар эшчәнлеге</td><td>Укытучы эшчәнлеге</td><td>Укучылар эшчәнлеге</td><td>Универсаль уку гамәлләре</td></tr>
<tr><td>I.Оештыру өлеше, мотивация.</td><td colspan="4">Кыңгырау чылтырый һәм тына-<br>Дәрескә чакыра ул безне.<br>Яңалык белергә, ачышлар ясарга<br>Әзерме биредә һәрберсе?<br>Әзер булсагыз, дәресебезне башлап җибәрәбез.</td><td>КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек</td></tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | итү<br>ШУУГ:<br>үзмаксат кую |
| II. Белемнәрне актуальләштерү. | 1. 1 класслар санлы җилпәзәләрегезне алыгыз.<br>- 3 артыннан килүче сан...<br>- 7 дән соң ничә килә?<br>- 6 ның алдында ничә тора?<br>- 8 кайсы саннарның арасында урнашкан?<br>- 4 нең күршеләрене күрсәтегез<br>- 9 дан 1 гә зуррак сан нинди?<br>2.Карточкалардагы | 1. Информация белән эшлиләр тиешле санны күрсәтәләр, үз җавапларын исбатлыйлар, иптәшләрен төзәтәләр<br>2. Информация | Конверттагы биремне дәфтәрләрдә үтәгез.<br>1. *Индивидуаль эш*<br>Саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.<br>2. *Парларда эш*<br>Карточкадагы санны төзеп языгыз. | 1. 1-23850, 230850, 2380,<br>2-79520, 790520, 7905<br>3-64762, 647062, 6476<br>4- 32012, 320120, 3210<br>2. 1 пар- илле ике мең сигез йөз (52800)<br>2 пар- ике йөз туксан мең алты йөз унике (290612) | *КУУГ :* укытучы һәм иптәшләрең белән уку гамәлләрен чишкәндә контрольдә тоту, төзәтүләр кертү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | саннарны кими бару тәртибендә тезегез. | белән эшлиләр үз җавапларын исбатлыйлар, иптәшләрен төзәтәләр | (слайд)<br><br><br><br>3. *Төркемдә эш*<br>Карточкаларны әйләндереп дәреснең кунагын белегез. | Экран буенча тикшерү, үз-үзеңне, иптәшеңне контрольләү<br>3.**КЫЗЫЛ КАЛФАК** | |
| III. Уку максатын кую. | 1.*Экран белән эш*<br>Укучылар, экранга игътибар итик әле. “Кызыл Калфак белән гөмбәләр җыю” (слайд)<br>- Ә соңгы кәрзиндә ничә гөмбә?<br>- Бик дөрес, берәү дә юк. Ә нинди сан куярбыз? | 1.Гөмбәләр санына туры килгән санны күрсәтәләр, экран белән дөреслеген тикшерәләр<br><br>-Берәү дә юк.<br><br>Проблемалы сорауга җавап бирүдә катнашалар, үз | 1. *Дәфтәрләрдә эш*<br>- Кызыл Калфак сезгә бирем алып килгән. Бирелгән зурлыкларны төркемнәргә бүлеп языгыз<br>**м, сәг, кг, мм, тәүл, см, ел, л, км, дм, мин , г**<br>- Төркемнәргә | 1. Карточкадан биремне үтиләр<br>**м, мм, см, дм**<br>**сәг, тәүл, мин**<br>**кг, г**<br><br><br><br><br>Укучылар **км** ны | *РУУГ:* максат кую, планлаштыру;<br><br>*ТБУУГ :* билгеләрне аеру максатыннан логик чылбыр төзү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | -Бүгенге дәрестә без “бернәрсә дә юк” төшенчәсен нинди сан белән тамгалап булуын белербез.<br>Кайвакытта була сан –Юк әйберне санасаң.<br>Ничәле саны икән соң инде ул?<br>2. Саннар рәтенә 0 санын урнаштыру. | фикерләрен дәлиллиләр.<br>Табышмакка җавап бирәләр.<br>- 0 саны.<br>2. Саннар рәтенә 0 санын урнаштыралар. | урнаштырганда кайсы зурлык белән кыенлык туды? Ни өчен?<br>- Кайсы төркемгә кертербез икән **км** ны<br>2. *Парларда эш*<br>- Бирелгән озынлык үлчәү берәмлекләре ярдәмендә тигезлекләр төзеп дәфтәрегезгә языгыз, бер-берегезгә ярдәм итегез.<br>3. – Кайсы үлчәү берәмлеге белән тигезлек төзи алмадыгыз? Ни өчен? | әле өйрәнмәгәнлекләрен икәнлеген әйтәләр.<br>- Озынлык үлчәү берәмлеге.<br>2. **м, дм, см, мм, км**<br>1 м = 10 дм, 1 м = 100 см, 1м=1000 мм<br>3. км белән төзи алмыйлар, өйрәнелмәгән үлчәү берәмлеге дип фикерлиләр | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Күзләр өчен күнегүләр | ***Күзләрне 0 саны буенча хәрәкәтләндерү. Чабучы ат артыннан күзәтү (слайд)*** | | | | |
| IV. Яңа белемнәр ачу. | 1. - 0 саны нәрсәгә охшаган? (слайд)<br><br>2. 0 санының цифры белән танышу. 0 цифры бер генә элементтан тора – зур овал. Язуны өстәге уң як почмактан аз гына төшеп башлыйбыз, шакмакның өске | 1. Укучылар үз фикерләрен җиткерәләр. Экранга карап күзаллауларын киңәйтәләр.<br>2. Экранны һәм укытучының тактада аңлатуын күзәтәләр, дәфтәрләрдә язалар | *1. Индивидуаль эш*<br>**<u>Километр</u>** - кыскартып: **км «кило» -** аңлата «мең»<br>Километр метрдан мең тапкыр зур **(1 км = 1000 м)**<br>2.- Км белән үлчәнә торган мисаллар китерегез.<br>(слайд) Ат сәгатенә 50-60 км юл үтә. Куян шулай ук | 1. Укып өйрәнәләр. Дәреслек белән дөреслеген тикшерәләр. Дәфтәрләрдә язалар **1 км = 1000 м**<br><br>2. Укучылар фикерләп җавап бирәләр.<br>Экран ярдәмендә белемнәрен үстерәләр. | *РУУГ:* прогнозлау ; логик-проблеманы чишү,<br>*КУУГ* информацияне табуда хезмәттәшлек итү, үз фикереңне ачык итеп җиткерү |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кырыена тидереп түгәрәклибез, аска төшерәбез һәм аннан соң өскә овал башына китерәбез.<br>- Ә хәзер дәреслектәге үрнәктән дә карап дәфтәрләрдә 0 цифрын язабыз. | Дәфтәрләрдә контур буенча йөртәләр, мөстәкыйль язалар | сәгатенә 60 км араны чаба ала. Машина белән 1 сәгатькә 90, ә самолет 800 дән артык км юл узарга мөмкин .<br>-Табышмак тыңлагыз.<br>Үзе күрмәсә дә, бүтәннәргә күрсәтә, Телсез, колаксыз булса да, санарга өйрәтә.<br>Олы юлларда чакрым баганалары утыртылган. Әлеге баганаларга ничә км юл узасы калганы язылган. | Укытучы һәм экрандагы рәсем ярдәмендә чакрым баганалары икәнлеген ачыклыйлар. **Км** белән ерак араларның озынлыгын үлчиләр дигән нәтиҗәгә киләләр. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3. Дәреслек буенча белемнәрне тикшерү<br>4 Тактада мисаллар эшләү (беренчесен) | 3. 48 бит №154<br><br>4 . 48 бит №155 | |
| V. Ял минуты. | Тупны иелеп алдым Гәүдәм белән иелдем<br>Баш очына күтәрдем Тупны баш аша чөйдем. | | | | |
| VI. Өйрәнгәннәрне ныгыту. | *1. Дәреслек белән эш.*<br>32-33 бит № 3, 5<br>1 нче бирем.<br>Рәсемнәрне карагыз әле.<br>- Беренче рәсемдә нәрсәләр ясалган ?<br>- Ничә яшелчә сурәтләнгән ?<br>- Алдагы рәсемдә нәрсә сурәтләнгән?<br><br>- Ничә җиләк – җимеш | 1. Укытучы ярдәмендә нәтиҗәләр ясыйлар.<br><br>- Яшелчәләр.<br><br>- Берничә.<br><br>-Җиләк – җимешләр һәм чәчәкләр.<br>- Берничә. | 1. *Индивидуаль эш.*<br>- Кызыл Калфакның әбисе Казанда тора. Ул анда ике юл аша бара ала. Ләкин ул кыскарак юлдан барырга тели. Кызыл Калфакка кыска юлны табарга ярдәм итегезче.<br> | 1. Карта ярдәмендә исәпләүләрне дәфтәрләрдә башкаралар. Иске Ашыт - Әтнә - Казан юлы кыскарак икәнен ачыклыйлар. | ТБУУГ: анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару.<br>РУУГ:<br>-уку гамәлләрен чишкәндә планлаштыру, контрольдә тоту, төзәтүләр кертү;<br>-үз-үзеңне ихтыяр буенча |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | сурәтләнгән?<br>- Соңгы рәсемдә нәрсә күрәсез?<br>-Ничә чәчәк сурәтләнгән?<br>-Бер чәчәк тә булмаган рәсемгә фишка куегыз. Бу очракта чәчәкләр ноль дип әйтәләр. (Укытучы 0 цифры язылган карточканы күрсәтә)<br>2. *Дәреслек буенча эш*<br>- Кызыл Калфак белән мисаллар чишик әле.<br>( слайд) | - Чәчәкләр.<br>- Берничә.<br>Фишка куялар.<br>2. Укучылар саннар рәте ярдәмендә мисаллар чишеп 1 дән 1 не алгач 0 булуын беләләр, алга таба саннан шул ук санны алгач | 2. *Парларда эш*<br>№157<br>3. №160<br>*1 нче өй эше*<br>Өлкәннәр ярдәме белән үзегезнең 1 атнада мәктәпкә бару, кайту озынлыгын исәпләгез | 2. 1 пар (1)-тактада, 2 пар (2)-урыннарда<br>3. 2х2х6=24(км)<br>2+2=4 км<br>4х6=24(км)<br>Җавап: 24 км юл уза | көйләү;<br>КУУГ: фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру |

<table>
<tr>
<td></td>
<td></td>
<td>0 буласына нәтиҗә ясыйлар<br>Укытучы ярдәме белән эшлиләр, бер-берсен тыңлыйлар.</td>
<td></td>
<td></td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td>VII. Укучыларның белемнәрен тикшерү</td>
<td>1. Дәфтәрләрдә эш<br>32 бит №3<br><br>2. Иҗади бирем<br>0 гә охшаган предметлар ясарга</td>
<td>1. Укучылар фикерләрен белдерәләр.<br>2. бублик, сушки, көпчәк, һ.б.</td>
<td>Дифференциаль эш.
<table>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td></tr>
<tr><td>5см1 мм = … мм</td><td>5см = … мм</td><td>1м = … дм</td></tr>
<tr><td>63мм =… см…мм</td><td>60мм = … см</td><td>1 дм =…см</td></tr>
<tr><td>7дм =… см</td><td>7дм = … мм</td><td>1 м =…. см</td></tr>
<tr><td>30 км =… м</td><td>3км =… м</td><td>1 км = ... м</td></tr>
</table>
</td>
<td>Карточкадагы биремнәрне үтиләр.</td>
<td>РУУГ:<br>Өйрәнгәннәр арасыннан кирәкле мәгълүматны аерып алу<br>ТБУУГ:<br>Фикерләүнең логик чылбырын төзү<br>КУУГ:<br>Сорауларга фикерләп җавап</td>
</tr>
</table>

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | бирү |
| VIII. Дәресне йомгаклау. Өй эше. Рефлексия. | 1.( слайд)<br>Мин → белдем<br>→ истә калдырдым<br>→ булдырдым | 1. Мин 0 берәү дә юк икәнне аңлатканын **белдем**.<br>Мин 0 санының урынын **истә калдырдым.**<br>Мин дөрес итеп 0 не **яза алдым**. | 1. 2 нче *өй эше*<br>2. (слайд)<br>Мин → белдем<br>→ истә калдырдым<br>→ булдырдым | 1.49 бит №159,161<br>2. Мин км ераклык үлчәү берәмлеге икәнен **белдем**<br>Мин 1 км= 1000 м икәнен **истә калдырдым**<br>Мин үлчәү берәмлекләре арасында бәйләнеш **төзи алдым** | *КУУГ: тулы итеп фикерләреңне әйтү*<br>*ШУУГ:* эшчәнлегеңә нәтиҗә ясау;<br>РУУГ: бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру |
| | 2. Смайликлар ярдәмендә кәефне күрсәтү.<br>3. Кызыл Калфак күчтәнәче белән сыйлану. | 2. Укучылар кәфләрен күрсәтәләр.<br>3. Бублик, сушки- 0 гә охшаган. Кызыл Калфакка | 3. Смайликлар ярдәмендә кәефне күрсәтү.<br>4. Кызыл Калфак күчтәнәче белән сыйлану. | 3. Укучылар кәфләрен күрсәтәләр.<br>4. Кызыл Калфакка үзләре белән булган өчен рәхмәт | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | күчтәнәчләре өчен рәхмәт әйтәләр. | | әйтеп күчтәнәче белән сыйланалар. | |